КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 декабрь г.Казань № 1231

2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карары белән расланды

2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – Фонд, субсидия) бирү механизмын билгели.

Субсидия бирү алымы – чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

2. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

3. Субсидия тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет акчасын алучы буларак Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

5. Субсидия күләме Фондның бирелгән финанс планы нигезендә әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен 2024 елга Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнар суммасы буларак билгеләнә.

6. Субсидия алу өчен Фонд субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Фонд чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Фонд экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Фонд БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

Фонд әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмый;

Фонд «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

Фондның бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

Фондның башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

Фонд үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки Фондның баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар булмау.

7. Субсидия алу өчен Фонд Министрлыкка түбәндәге документлар теркәлгән, Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имза куелган, әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасындагы форма буенча тутырылган заявка тапшыра:

Фонд тарафыннан Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарның гамәлгә ашырылуы чагылдырыла торган, ишегалды территорияләре күрсәтелгән, әлеге Тәртипнең 2 нче кушымтасындагы форма буенча төзелгән Фондның финанс планы;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга кертелә торган барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләре;

Фонд җитәкчесенең (аның вазыйфаларын башкаручы затның) вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан имзаланган әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве турында белешмә кәгазе;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Фонд турында мәгълүмат, Фонд тапшыра торган заявка, субсидия бирүгә бәйле Фонд турында башка мәгълүмат бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалык.

Документлар кәгазьдә һәм (яки) электрон чыганакларда бирелергә мөмкин.

Кәгазьдә тапшырылган барлык документлар аңлаешлы итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр, Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзасы белән расланган һәм аның мөһере (булганда) беркетелгән төзәтмәләрдән тыш, рөхсәт ителми. Кәгазьдә тапшырылган заявкаларның барлык битләре тегелгән, номерланган, Фонд җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) имзасы белән расланган булырга тиеш.

Әлеге пунктта һәм әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән белешмәләрнең һәм тапшырылган документларның дөреслеге өчен Фонд Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Фонд, заявка белән бергә, үз теләгенә карап, Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

заявка бирү датасына кадәр өч айдан да иртәрәк булмаган вакытта Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан бирелгән өземтә күчермәсен;

салым органында исәпкә куелу турында документ күчермәсен;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыюны түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агенты) тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар һәм аны электрон рәвештә тапшыру форматының үтәлеше турында белешмә формасын раслау турында» 2022 елның 23 ноябрендәге ЕД-7-8/1123@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча

телекоммуникация элемтә каналлары буенча яки салым түләүченең шәхси кабинеты аша электрон формада яисә кәгазьдә салым органы мәгълүматлары нигезендә белешмә кәгазен формалаштыру датасына карата салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләрнең үтәлеше турында белешмә кәгазен.

Фонд тарафыннан әлеге пунктта күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмат алышу тәртибендә соратып ала.

9. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

әлеге Тәртипнең 7 пунктында күрсәтелгән документларны заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә карап тикшерә;

заявка теркәлгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә субсидия бирү (бирүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында Фондка язмача хәбәр бирә.

10. Фондка субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

Фондның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

Фонд тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 7 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Фонд тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

11. Субсидия Министрлык һәм Фонд арасында төзелгән килешү нигезендә бирелә. Килешү Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләре, субсидияне күчерү тәртибе һәм сроклары;

субсидия бирү тәмамлана торган төгәл дата һәм нәтиҗәсенең ахыргы күрсәткече (йомгакларның конкрет микъдари тасвирнамәсе);

Фонд тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсе зурлыгына ирешү турында хисап һәм финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе, шулай ук өстәмә хисап бирү сроклары, тәртибе һәм формасы (кирәк булганда);

Фондның, Фонд белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә

ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүгә ризалыгы.

Фонд тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр;

Фонд, шулай ук Фонд белән төзелгән шартнамәләр (килешүләр) нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында шарт;

элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкин булмавына китерә торган итеп киметкән очракта яки яңа шартлар белән килешүгә ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт, килешүнең яңа шартларын килештерү тәртибе;

Министрлык белән Фонд, кирәк булганда, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

12. Фонд кушылу, кушу яки үзгәртеп оештыру рәвешендә үзгәртеп оештырылганда, килешүгә йөкләмәдә зат алышыну өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәреш кертелә, килешүдә хокук варисы булып торган юридик зат күрсәтелә.

Фонд бүлү, аерып чыгару рәвешендә үзгәртеп оештырылган, шулай ук Фонд бетерелгән очракта, килешү, берьяклы тәртиптә килешүне өзү турында хәбәрнамә булдырып һәм, Фонд тарафыннан үтәлмәгән, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган йөкләмәләр һәм субсидиянең файдаланылмый калган өлешен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару турында мәгълүматны чагылдырып, килешү буенча йөкләмәләрне үтәү турында акт төзеп өзелә.

13. Субсидия, Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң килә торган 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында Фонд ачкан исәп-хисап яки корреспондентлык счетына күчерелә.

14. Килешүдә күрсәтелә торган субсидия бирү нәтиҗәсе – субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча ирешү срогы белән Татарстан Республикасында кимендә 600 ишегалды территориясен төзекләндерү эшләрен башкару.

15. Әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган итеп кимителгән очракта, Министрлык бирелә торган субсидия күләмен үзгәртү турында карар кабул итә һәм Фондка килешүгә үзгәреш кертү кирәклеге турында хәбәр итә.

16. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнар юнәлешләренә түбәндәге чыгымнар керә:

төзекләндерү объектларының проект-смета документациясен эшләү;

юл эшләрен башкару;

урам яктырткычларын урнаштыру;

кече архитектура формаларын урнаштыру.

17. Фонд квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасына теркәлә торган формалар буенча субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап кертә.

18. Министрлык тапшырылган хисапларны Министрлыкка кергән датадан бер эш көне эчендә теркәп бара. Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешү турындагы хисапны һәм финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисапны карап тикшерә, Фондның хисапларын кабул итү турында яисә, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешмәгән яки финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашырганда ачыкланган хокук бозулар булган очракта, Фондның хисапларын кабул итмәү турында карар кабул итә һәм, алынган көннән 10нчы календарь көннән дә соңга калмыйча, Фондка аларны кабул итү (кабул итүдән баш тарту) турында хәбәр итә.

19. Хисап финанс елында финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган акчаның файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан килешүдә билгеләнгән тәртиптә әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш).

Хисап финанс елында файдаланылмаган акча юнәлешләренә ихтыяҗ булган очракта, әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Фонд Министрлыкка, хисап елыннан соң килә торган елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, шундый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, Фондтан әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗ булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында хисап финанс елында файдаланылмаган субсидиянең калган өлешен юллау ихтыяҗы булу турында карар кабул иткән очракта, Министрлык һәм Фонд арасында мондый карар кабул ителгән көннән башлап календарь көннәрдә исәпләнә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

20. Министрлык Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрүне гамәлгә ашыра.

21. Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүне һәм субсидия бирү нәтиҗәләрен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыра торган вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган нәтиҗәләргә

ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.

22. Бирелгән субсидия акчасы субсидия биргәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия бирү шартлары Фонд тарафыннан бозылган очракта, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешелмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты кеременә тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

23. Әлеге Тәртипнең 19 һәм 22 пунктлары нигезендә субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтарудан баш тартылган очракта, Министрлык Фондның алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарудан баш тарту турындагы хәбәрен алган көннән яки Министрлыкның язма таләбендә күрсәтелгән, алынган акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле рәвештә кире кайтару вакыты чыкканнан соң календарь көннәрдә исәпләнә торган җиде көн эчендә мәҗбүри тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

24. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны, аны бирү шартларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2025 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры

______________________________________________

(тулысынча) Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды (алга таба – Фонд) җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат)

______________________________________________

_________________________________ дан (нан)

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирүгә
заявка

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 28 декабрь, 1231 нче карары белән расланган 2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибе нигезендә _______________________________________________________

(Фонд исеме)

Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен ______________________

(суммасы саннар белән)

(_________________________________) сум ____ тиен күләмендә субсидия бирүегезне

(суммасы сүзләр белән)

сорыйм.

Әлеге заявкада бирелгән белешмәнең дөреслеген һәм тулылыгын раслыйм.

Дөрес булмаган белешмә һәм документлар биргән өчен җаваплылык турында кисәтелдем.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмә һәм документлар тапшыру, субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар һәм тәртип бозу ачыкланган очракларда, бирелгән субсидия Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарырга бурычлы булуым турында хәбәр ителде.

_______________________________________________________________ ның (нең)
(Фонд исеме)

субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә түбәндәгеләрне раслыйм:

Фонд чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

Фонд экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Фонд БМО уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

Фонд «Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты булып тормый;

Фондның бердәм салым исәбендә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү буенча бурычы

юк яисә Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән күләмнән артмый;

Фондның башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча срогы чыккан бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча башка срогы чыккан (җайга салынмаган) бурычы юк (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән очраклардан тыш);

Фонд үзгәртеп оештыру (Фондка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәгән, Фондның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки Фондның баш бухгалтеры (булганда) турында мәгълүматлар юк.

_______________________________________________________ га карата
(Фонд исеме)

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерү (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга ризамын.

Фонд җитәкчесе
(аның вазыйфаларын
башкаручы затның) ________________ / ______________________________________________________/
(имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда))

М.У.

Дата: 20__ ел, «__» __________

2024 елда Татарстан Республикасында ишегалды территорияләрен төзекләндерү чараларын тормышка ашыруга бәйле устав эшчәнлеген тәэмин итү өчен Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

## Татарстан Республикасында уңайлыклары булган мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фондының финанс планы

| Т/с | Муниципаль берәмлек исеме | Объектның адресы һәм исеме | Каты өслекләр мәйданы, кв.метр | Юл эшләрен башкару кыйммәте, сум | Кече архитектура формаларын урнаштыру кыйммәте, сум | Урам яктырткычлары җайланмасы кыйммәте, сум | Гомуми кыйммәте, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Барысы бергә, шул исәптән: | | | | | | |
| | проект-смета документациясен эшләү кыйммәте | | | | | | |
| 1. | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | |
| …. | | | | | | | |

Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат)
_____________/ ____________________________________________/
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

М.У.

Дата: 20___ ел, «___» _________

Килештерелде
Татарстан Республикасында төзекләндерелгән мохит булдыруга ярдәм күрсәтү фонды
_________/ ____________________________________________/
(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булганда)

М.У.

Дата: 20___ ел, «___» _________

_________________________________________________________________